


# Татар телен дөньядагы интерактив белем бирүнең иң яхшы практикаларын кулланып өйрәнегез!

Онлайн-мәктәпне гамәлгә куючылар - Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы белән EF Education First компаниясе. Ул, татар теле белән кызыксынучы ватандашларның күпсанлы мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов кушуы буенча эшләнгән.

«АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе Татарстанда яшәүчеләргә генә түгел, чит илләрдәге татар мәдәнияте һәм теле белән кызыксынучыларга да татар телен дөньяның теләсә кайсы почмагында тәүлегенә 24 сәгать бушлай өйрәнү мөмкинлеген бирә.

Татар телен комплекслы һәм эзлекле өйрәнү өчен төзелгән «АНА ТЕЛЕ» онлайн-мәктәбе EF Education First ның чит телләр укытуда кулланыла торган алдынгы технологияләренә нигезләнгән һәм үз эченә уникаль эчтәлекне ала.



«АНА ТЕЛЕ» Татарстан һәм EF лингвистлары һәм башка белгечләре хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә булдырылды. Татарстан Республикасы уку курсын һәм барлык интерактив медиа материалларын эшләде, ә EF проектка академик консалтинг һәм техник үсеш өлкәсендәге тәҗрибәсен кертте.

## «АНА ТЕЛЕ»

**9** дәрәҗә

**72** бүлек

**288** дәрес

**1676** күнегү

**9** дәрәҗә тесты

**288** видеоклип

**10950** аудиофайл

**6795** рәсемнән тора

Дәрәҗә тестын үтүчеләр өчен сертификат алу мөмкинлеге каралган.

**Anatele.ef.com сайтына теркәлеп, бүген үк татар телен өйрәнә башлагыз!**

instagram.com/tatar.anatele facebook.com/groups/tatar.anatele vk.com/anateletat